*Муниципаль тур*

**Рус телендә гомуми белем бирү оешмаларының**
**татар төркемнәрендә белем алучы укучылар өчен олимпиада биремнәре**
***2017/2018 нче уку елы***

**XI сыйныф**

**Үткәрү вакыты – 180 минут**
**Максималь балл -71**

1. **Текстны татарчага тәрҗемә итеп языгыз.**

**Что такое культура речи?**

Культура речи – это правильность, точность, выразительность и разнообразие речи. Правильность речи – это соблюдение норм русского литературного языка. Точность речи достигается четким выбором наиболее подходящего синонима. Культура речи, однако, не может ограничиваться только правильностью и точностью. Любой говорящий не может монотонно и сухо перечислять факты и цифры, повторять заученные фразы. Чтобы убедить своих слушателей или читателей, он должен говорить страстно. Речь должна быть выразительной. А выразительность речи создаются употреблением пословиц и фразеологизмов, сравнений, метафор, риторических вопросов. *(По В. Кодухову)*

**II. Берәр дөрес җавапны билгеләгез.**

1. Кайсы рәттәге сүзләрдә күпнокталар урынына “ң” хәрефе языла?
   - o боры...гы, кү...ел
   - o ча..гы, мо...лы
   - o са...гырау, төн...ге
   - o иртә...ге, кара...гы
2. Артык сүзне табыгыз.
   - o имән
   - o каен
   - o усак

- агач

3. Мәгънәләре буенча туры килә торган антонимнарны куегыз.

Ачык ишек ○ ябык ишек
○ караңгы ишек
○ йомык ишек
○ төссез ишек

Ачык йөз ○ ябык йөз
○ караңгы йөз
○ йомык йөз
○ төссез йөз

Ачык кеше ○ ябык кеше
○ караңгы кеше
○ йомык кеше
○ төссез кеше

4. Сүз ясалышы ягыннан кайсы рәт «артык»?

- аучы
- җырлачы
- утынчы
- ташчы

5. Нокталар урынына тиешле бәйлекләр языгыз.

- Мин сезнең ... киңәшергә телим.
- Көннәр салкынаю ..., бүген укулар булмады.
- Газетада Исламның китабы ... мәкалә басылды.
- Аңа сәгать ... яңгыр астында торырга туры килде.

6. Төшем юнәлешендәге фигыльләр генә булган рәтне күрсәтегез.

- Китергән (файда), җырлаткан (җыр).
- Киенгән (кеше), язылган (хат).
- Уздырган (кичә), сөйләшкән (сүз).

○ Ябылган (юрган), юылган (урын).

7. Нокталар урынына кирәкле сүзләр өстәп, сул баганада бирелгән сүзләрнең мәгънәләрен уң баганадан табып языгыз.

| | |
|---|---|
| Арыслан | ... икмәк |
| Бәрәңге | ... ягулык |
| Газ | ... хәбәрчесе |
| Сыерчык | ... патшасы |

8. *Бүген күп йөрелде* җөмләсенең дөрес аңлатмасын табыгыз.

○ Бер составлы фигыль җөмлә.

○ Бер составлы атау җөмлә.

○ Бер составлы исем җөмлә.

○ Дөрес җавап бирелмәгән.

**III. Иҗади биремнәр.**

1. Тел турында 3 мәкаль языгыз.

2. 11 җөмлә күләмендә “Безнең сыйныф җитәкчесе” исемле хикәя языгыз.